**Ф.С. Сәйфуллина, З.Ф. Акмалова**

*Казан федераль университеты, Казан*

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ МАТЕРИАЛЛАРЫН КУЛЛАНУ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ (Т.ГАЛИУЛЛИН ХЕЗМӘТЛӘРЕ БУЕНЧА)

*Аннотациия. В данной статья посвящена методическим аспектам использования литературно- критических статей ученого и литературного критика Талгата Галиуллина на уроках татарской литературы. В работе анализируются книги «Шигърият баскычлары» и «Яктылык» с позиции выявления их возможности использования в практике преподавания родной литературы.*

*Ключевые слова: татарская литература, методика преподавания татарской литературы, литературно-критическая деятельность Талгата Галиуллина.*

*Abstract. This article is devoted to methodological aspects of using literary critical articles scholar and literary critic Talgat Galiullin the lessons of Tatar literature. The paper analyzes the book "Shigriyat baskychlary" and "Yaktylyk" from the perspective of identifying their potential use in the practice of teaching the native literature.*

*Key words: Tatar literature, teaching methodology of Tatar literature, literary-critical activity Talgat Galiullin.*

Матур әдәбиятның башка берни белән дә алыштырып булмый торган мөстәкыйль әһәмияте һәм билгеләмәсе бар. Ул халыкның гасырлар буена бөртекләп җыела килгән акыл һәм рухи байлыгын тәшкил итә. Әлбәттә, рухи хәзинә язма сүз сәнгате белән генә чикләнми. Әдәби әсәрләрнең төп төзү материалы булган тел үзе генә дә иңләп булмастай дәрьяны хәтерләтә. Болар янына тагын халкыбызның көе-моңы, көлү чаралары һәм биюе, рәсем һәм сәхнә сәнгате, матбугат фәлсәфәсе, мәгърифәте, гореф-гадәтләре һәм уен-йолалары, әхлак принциплары, тарихи истәлекләре, ювелир-һөнәр осталыгы һәм башкалар килеп кушыла. Матур әдәбият – әнә шул җанга якын, газиз олы хәзинәнең бик мөһим бер өлеше ул.

Билгеле, мәктәп программаларында аны бөтен тулылыгы белән чагылдыру мөмкин түгел. Шуңа күрә дә, халкыбызның олы хәзинәсен укучы күңеленә тулаем җиткерү бурычы укытучылар җилкәсенә төшә.

Бүген укытучыдан күп нәрсә таләп ителә, тиз үзгәрүчән, компьютер, интернет челтәрләре популяр заманда, укытучы кеше укучыларны китап уку,

матур әдәбият белән дә кызыксындыра белергә тиеш. Бу – шактый көч, зур осталык сорый торган процесс. Дәрескә куелган бурычларны тормышка ашыру өчен укытучы тиешле методик алымнарны сайлап ала белергә, язучы иҗатына кагылышлы материаллар белән киң күләмдә таныш булырга тиеш. Бу мәкаләдә хезмәтләре өйрәнү объекты буларак алынган Т. Галиуллинның тәнкыйди эшчәнлеге, күп төрле фәнни тикшеренүләре, басылып чыккан күпсанлы хезмәтләре бу эшкә зур мөмкинлек тудыра.

Әлеге мәкаләнең максаты – Т.Галиуллинның «Яктылык» һәм «Шигърият баскычлары» җыентыкларында урын алган әдәби тәнкыйть материалларының мәктәптә белем бирү процессында ни рәвешле кулланыла алу мөмкинлеген ачыклауга – ягъни бу хезмәтләрне методик аспектта өйрәнүгә багышлана.

Мәктәптә дәресләр укыту Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган программалар нигезендә башкарыла. Бу эштә без әлеге министрлык тарафыннан уздырылган конкурста җиңеп чыккан, КФУ профессоры Ф.Г.Галимуллин, профессор Ф.Ә.Ганиева һәм Татарстанның атказанган укытучысы, Халык мәгарифе отличнигы Д.Ш.Сибгатуллиналар авторлыгында төзелгән «Татар телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләренең 1-11 нче сыйныфлары өчен татар әдәбиятын укыту программасы»на таянып эш иттек. [1-11 өчен татар әдәбиятын укыту программасы, 2013. – 112 б.]

Программадагы бурычларның беренче икесе укытучы эшчәнлеге белән бәйле булса, соңгы икесе – укучының актив эшчәнлеген таләп итә. Укытучыга эш барышында аерым тема, әсәрне нинди юллар белән балаларга җиткерү, дәрестә кайсы өлешләргә игътибар итү һәм ничек анализ бирү һ.б. турында бик күп сорауларга җавап табарга туры килә. Галимнең бу мәкаләдә өйрәнелә торган фәнни-тәнкыйди мәкаләләрне үз эченә алган китаплары, һичшиксез, укыту барышында, я булмаса аерым мәсьәләләрне ачыклауда файдалы, уңай нәтиҗәләр бирә алыр иде.

Укучыга үзлектән хәзерләнгәндә дә Т.Галиуллин китаплары зур белем чыганагы булып тора ала. Китаплар, беренче чиратта, укучыны китап сөюче

шәхес итеп тәрбияли. Урта сыйныфларда мәкаләләре укытучы биргән белемнәргә өстәмә мәгълумат, яңа белемнәр бирүче чыганак булып тора ала. Югары сыйныфларда исә әдәби тәнкыйть материалларын файдалану тагын да киңрәк масштабларда кулланырга мөмкинлек тудыра. Өстәмә мәгълүмат булудан тыш, төрле күзәтү, семинар дәресләрендә чор шигъриятен өйрәнгән вакытта, иҗатчылар турында тулырак мәгълүмат алу өчен Т.Галиуллинның әдәби тәнкыйть материалларына мөрәҗәгать итү үзен аклый. Аннан соң, төрле мөстәкыйль эшләр эшләгәндә, рефератлар, сочинениелар язганда һәм класстан тыш эшләр үткәргәндә Т.Галиуллинның хезмәтләре теманы фәнни нигездә, тирәнтен ачарга ярдәм итәчәк.

Т.Галиуллинның үзебез өйрәнгән «Яктылык» [Галиуллин, 2002: 226], «Шигърият баскычлары» [Галиуллин, 2011: 319] китапларында урын алган әдәби тәнкыйть материалларының аерым бер язучылар иҗатына багышланган булуыннан чыгып, аларны мәктәптә уку-укыту процессында куллану мөмкинлекләрен алда телгә алынган программага низеләнеп, гамәли яктан да ачыклап китик.

Әлеге трограммалар буенча, Г.Тукай иҗаты түбән сыйныфлардан алып югары сыйныфларга кадәр өйрәнелә. Нигез итеп алынган программага күз салсак, 5-7 нчы сыйныфларда аның шигъриятенә басым ясалса, 10 нчы сыйныфта исә Г.Тукай иҗаты һәм тормыш юлы тулаем алып өйрәнелә. Баштарак шагыйрьнең тәрҗемәи хәле турында моңарчы алган белемнәрне искә төшерү һәм гомумиләштерү, яңа фактлар белән таныштыру максат булып торса, югары сыйныфларда иҗатына караган үзенчәлекләргә ныграк басым ясала. Г.Тукайны тәнкыйтьче буларак өйрәнү дә күздә тотыла. Шушы теманы үткәндә өстәмә мәгълүмат буларак укытучы Т.Галиуллинның «Яктылык» җыентыгына кертелгән «Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь» [3: 22-23], «Тукай: шәхес һәм шигърият бердәмлеге» [3: 24-31], «Шигърият баскычлары» китабына кертелгән «Тукай һәм XX гасыр татар шигърияте» [2: 20-27], «Тукай шигырьләрен яңадан укыганда» [2: 30-31] мәкаләләренә таянып эш итә ала.

Г.Исхакый иҗатын программада җиденче һәм унынчы сыйныфларда өйрәнү каралган. Җиденче сыйныфта язучының тәрҗемәи хәле һәм хикәяләре өйрәнелсә, унынчы сыйныфта Г.Исхакыйның милләт өчен көрәш юлы, сөргендә булуы, Төркиягә китүе, илгә яңадан кайтып, революцион көрәшне дәвам иттерүе, романнары һәм повестьлары өйрәнелә. Бу очракта Т.Галиуллинның «Яктылык» китабына кертелгән «Гаяз әфәнде – шагыйрьдер» [3: 32-73] дигән мәкаләсендәге Г.Исхакыйның шагыйрь булуына басым ясаган фикергә игътибар итергә мөмкин. «Исхакый һәм татар шигърияте» [2:19-22] мәкаләсендә Т.Галиуллин әдип иҗатында өч мөстәкыйль юнәлешне аерып чыгара, мәкалә укучыга Г.Исхакый иҗатын тирәнтен өйрәнергә ярдәм итә.

Мәктәп программасында Х.Туфан иҗаты алтынчы һәм унберенче сыйныфларда өйрәнелә. Өстәмә материал буларак Т. Галиуллинның «Хәсән Туфан иҗатында XX гасыр сурәте» [3: 99-105] мәкаләсе кулланыла ала.

Шагыйрь И.Юзеев иҗаты алтынчы сыйныфта өйрәнелә, унберенче сыйныфта исә өстәмә уку өчен тәкъдим ителә. Бу теманы үткәндә укытучыларга һәм укучыларга Т.Галиуллинның «Яктылык» китабындагы «Шигърияттә үз биеклеге бар!» [3: 120-125] дигән мәкаләсе ярдәмгә килә ала.

Унберенче сыйныфта программа буенча Р.Харис, М.Әгъләмов иҗатлары өйрәнелә. Без анализлаган хезмәтләрдә Т.Галиуллинның алар иҗаты белән бәйле мәкаләләре дә бар. «Яктылык» китабындагы «Ренат Харис поэмаларында дөнья сурәте» [3: 260-278] һәм «Шигърият баскычлары» китабындагы «Шагыйрьләр – изгеләр нәселеннән» [3: 192-214] мәкаләләре поэзия турында мәгълүмат бирү, шигърияттә заманчалык рухы һәм шагыйрьләр иҗатындагы үзенчәлекләрне ачыкларга ярдәм итә.

Программада урта сыйныфта дәрестән тыш уку өчен Ш.Бабич, Р.Гаташ, Р.Харис иҗатлары тәкъдим ителә. Т.Галиуллин китапларында да алар турында мәкаләләр урын алган. «Шәехзадә Бабич – сатира остасы» [3: 89-98], «Ренат Харис поэмаларында дөнья сурәте» [3: 260-278], «Шагыйрьләр – изгеләр нәселеннән» [3: 192-214] мәкаләләре укытучыга һәм укучыга чор поэзиясен яңача күзаллауга ярдәм итә.

Югары сыйныфларда чор әдәбияты ныклап өйрәнелә. Т.Галиуллинның без өйрәнгән «Яктылык» һәм «Шигърият баскычлары» китаплары XX-XXI гасыр башы шигъриятен өйрәнүгә багышланган. Анда автор ике дәвер әдәбиятының эчке уртаклыкларын, күчемлелек-дәвамлылыгын күздә тотып өйрәнү кирәк дигән нәтиҗә чыгара. Әдәбиятның бер чорын икенчесеннән аерып торган үзенчәлекләргә караганда, аларны якынлаштырып, җанлы җепләр белән бер-берсенә бәйләп торган сыйфатларның күбрәк булуын күрсәтә.

Шуңа күрә дә, безнеңчә, чор әдәбиятын яңа күзлектән чыгып бәяләгәндә галимнең «Заман таләбе – шигърият асылы» [3: 148-184], «Тынчу елларның тынгысыз шигърияте» [3: 185-215], «Милли яңарыш чоры шигърияте» [3: 216-259], «Егерменче еллар татар шигърияте» [2: 47-90], «Утызынчы еллар татар шигърияте» [2: 91-125], «Хәзерге татар шигърияте» [2: 126-171] кебек күзәтү характерындагы мәкаләләрен файдалану аеруча отышлы. Әлеге язмалардан файдаланып, укытучы дәресен укучыларга кызыклы һәм файдалы да итеп оештыра ала.

Без карап чыккан мисаллардан күренгәнчә, тәнкыйтьче галим Т.Галиуллинның китапларындагы әдәби тәнкыйть мәкаләләрен белем бирү процессында укытучыга куллану мөмкинлекләре гаять киң. Мәктәп укучысын уйлый-уйлана, яза һәм сөйли белә торган шәхес итеп үстерү өчен бу хезмәтләр зур таяныч булып тора. Әдәби-тәнкыйть мәкаләләренә таяну мәктәптә татар әдәбиятын укытуның сыйфатын күтәрә, укытучыга һәм укучыга бик зур хәзинә ача.

**Әдәбият:**


1. 1-11 сыйныфлар өчен әдәбият укыту программасы. – Казан: Мәгариф, 2013. 112 б.
2. Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары. – Казан: Мәгариф, 2002. 226 б.
3. Галиуллин Т.Н. Яктылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 319 б.